Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино
авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 2**

Юлсубино авылы 2019 елның 05 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 2019 елның 06 октябрь –да гы "Җир салымы турында" 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 29 сентябрендәге "Россия Федерацисе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында" 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 ноябрендә ге 12 номерлы, 2015елның 29 маендагы 11 номерлы, 2017елның _ 22 августындагы 11 номерлы, 2019 елның 13 июнендәге 8 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары билгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән гайре) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык

эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре) җир кишәрлекләренә карата -0,3%”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино җирлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56 нчы йорт, Ямаш авылы, Һ.Такташ урамы, 3в йорт,адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге
Башлыгы Гатиятов Х.Х.